БАВЛИНСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ ШӘҺӘРЕ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

28.08.2020 Баулы шәһәре № 139

«Баулы шәһәре» муниципаль берәмлегенең «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлегенең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 20 апрелендәге 72 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләр башлыкларының, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларының, депутатларның, җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы сайланулы органнары әгъзаларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең айлык акчалата түләвен һәм муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларын арттыру турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 6 августындагы 658 номерлы карары нигезендә Баулы шәһәр Советы КАРАР ИТТЕ:

«Даими нигездә вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге муниципаль хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 20 апрелендәге 72 номерлы Баулы шәһәр Советы карарына (Баулы шәһәр Советының 2018 елның 28 сентябрендәге 89 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр

белән) 2020 елның 1 октябреннән түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләмнәре авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгеченең вазыйфаи окладыннан чыгып исәпләнә;

авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгеченең вазыйфаи оклады күләме 11498 сум тәшкил итә.».

Баулы шәһәре Мэры,
шәһәр Советы Рәисе — Р.Х. Гатиятуллин